КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 декабрь г.Казань № 1110

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче; 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

6.2.4 нче пунктта:

2 нче таблицада:

2 графаның исеменә «һәм һөнәри стандартлар буенча вазыйфалар исеме» сүзләрен өстәргә;

2 графаның 2 нче пунктына «, комплексლы тернәкләндерү буенча белгеч (реабилитолог)» сүзләрен өстәргә;

3 нче таблицада:

2 графаның 1 нче пунктына «, комплекслы тернәкләндерү буенча белгеч (реабилитолог)» сүзләрен өстәргә;

3 графаның 1 нче пунктына «, комплекслы тернәкләндерү буенча белгеч (реабилитолог) вазыйфалары» сүзләрен өстәргә;

6.9 нчы пунктта:

беренче абзацта «Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә икенче һәм өченче дәрәҗәләрдәге һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә,» сүзләреннән соң «гаилә белән эшләү буенча белгеч» һәм «комплекслы тернәкләндерү буенча белгеч (реабилитолог)» вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә,» сүзләрен өстәргә;

уникенче абзацта «Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә өченче дәрәҗәләрдәге һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә,» сүзләреннән соң «гаилә белән эшләү буенча белгеч» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләргә» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларына һәм эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

4.12 нче пунктның 1 нче таблицасында:

2 графаның исемендә «баш», «өлкән» вазыйфаи исемнәрен» сүзләреннән соң «һәм һөнәри стандартлар буенча вазыйфалар исемен» сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «6. | Кадрлар бүлеге (махсус бүлек һ.б.) башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, кадрлар әзерләү буенча инженер, табельче, кадрлар буенча эш башкару белгече, персоналы булган эшләрне документлар белән тәэмин итү буенча белгеч, персоналны документлар белән тәэмин итү буенча белгеч, персонал буенча | кадрлар бүлеге (махсус бүлек һ.б.) башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, кадрлар әзерләү буенча инженер, инструктор-дактилолог, һөнәри консультант, юрисконсульт, табельче, кадрлар буенча эш башкару белгече, персоналы булган эшләрне документлар белән тәэмин итү буенча белгеч, персоналны документлар белән тәэмин итү |

| | | |
|---|---|---|
| | белгеч, персоналны сайлап алу буенча белгеч, персонал буенча белгеч, персоналның аттестациясен бәяләү буенча белгеч, персоналны үстерү һәм укыту буенча белгеч, персонал карьерасын үстерү буенча белгеч, хезмәтне нормалаштыру һәм хезмәт өчен түләү буенча белгеч, хезмәтне оештыру һәм хезмәт өчен түләү буенча белгеч, компенсацияләр һәм ташламалар буенча белгеч | буенча белгеч, персонал буенча белгеч, персоналны сайлап алу буенча белгеч, персоналның аттестациясен бәяләү буенча белгеч, персоналны үстерү һәм укыту буенча белгеч, персонал карьерасын үстерү буенча белгеч, хезмәтне нормалаштыру һәм хезмәт өчен түләү буенча белгеч, хезмәтне оештыру һәм хезмәт өчен түләү буенча белгеч, компенсацияләр һәм ташламалар буенча белгеч»; |

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «13. | Матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире, товар белгече, агент, сатып алулар буенча агент, тәэмин итү буенча агент, йөкләр ташу буенча экспедитор, административ-хуҗалык белән тәэмин итү буенча белгеч, офис-менеджер, административ-хуҗалык бүлекчәсе башлыгы, административ-хуҗалык бүлекчәсе җитәкчесе, сатып алулар буенча белгеч, контракт буенча хезмәт хезмәткәре, контракт буенча идарәче, сатып алулар буенча өлкән белгеч, сатып алулар буенча консультант, бүлекчә җитәкчесе урынбасары, бүлекчә җитәкчесе, контракт буенча хезмәт җитәкчесе | матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире, товар белгече, агент, сатып алулар буенча агент, тәэмин итү буенча агент, тәэмин итү буенча икътисадчы, товар белгече, йөкләр ташу буенча экспедитор, административ-хуҗалык белән тәэмин итү буенча белгеч, офис-менеджер, административ-хуҗалык бүлекчәсе башлыгы, административ-хуҗалык бүлекчәсе җитәкчесе, сатып алулар буенча белгеч, контракт буенча хезмәт хезмәткәре, контракт буенча идарәче, сатып алулар буенча өлкән белгеч, сатып алулар буенча консультант, бүлекчә җитәкчесе урынбасары, бүлекчә җитәкчесе, контракт буенча хезмәт җитәкчесе»; |

33 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «33. | Инженер-электроник (электроник), исәпләү (мәгълүмати-исәпләү) үзәге техникы, мәгълүмат-коммуникация технологияләре бүлегенең кече белгече, мәгълүмат-коммуникация технологияләре бүлеге менеджеры, кече система администраторы, система администраторы, белгеч, инженер, система | инженер-электроник (электроник), исәпләү (мәгълүмати-исәпләү) үзәге техникы, инженер, инженер-программист (программист), техник-программист, техник, мәгълүмат-коммуникация технологияләре бүлегенең кече белгече, мәгълүмат-коммуникация технологияләре бүлеге менеджеры, ке- |

| | | |
|---|---|---|
| | инженеры, мәгълүматлар базалары администраторы, төп белгеч, төп система инженеры, өлкән система администраторы, баш система администраторы | че система администраторы, система администраторы, белгеч, инженер, система инженеры, мәгълүматлар базалары администраторы, төп белгеч, төп система инженеры, өлкән система администраторы, баш система администраторы». |

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин